**СОВЕТ АЛЕКСАНДРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**422613 н.п. им. «25 Октября»**
**тел: 8-(84378) -3-54-22**
**факс: 8-(84378) -3-54-22**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛЕКСАНДР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**422613 н.п. им. «25 Октября»**
**тел: 8-(84378) -3-54-22**
**факс: 8-(84378) -3-54-22**

# К А Р А Р

**№ 4** **2019 елның 14 мартыннан**

**Александровка авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 ноябреннән №47 “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александровка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт хакында Кагыйдәләр турында”гы карарына өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертү турында**

2007 елның 2 мартыннан № 25-ФЗ “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законны, 2008 елның 25 декабреннән № 273-ФЗ “ Коррупциягә каршы көрәш турында” Федераль законны үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июненнән № 50-ЗРТ Кодексы, “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александровка авыл җирлеге” Уставы нигезендә Лаеш муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 ноябреннән № 47 “Лаеш муниципаль районы Александровка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Кагыйдәләр хакында”гы Карарына кушымтага ярашлы төстә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга) һәм җирлек территориясендә махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемә алам.

**Башлык – Александровка авыл**
**җирлеге Советы рәисе вазифасын**
**башкаручы** **Э.А.Мингалиева**